КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2023 ел, 19 июнь

г.Казань

№ 729

Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау өчен кирәкле көчләрне һәм чараларны әзерләү һәм әзер булган хәлдә тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау өчен кирәкле көчләрне һәм чараларны әзерләүне һәм әзер булган хәлдә тотуны камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау өчен кирәкле көчләрне һәм чараларны әзерләү һәм әзер булган хәлдә тоту турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына муниципаль берәмлек халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау өчен кирәкле көчләрне һәм чараларны әзерләүне һәм әзер булган хәлдә тотуны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 19 июнь, 729 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен
гадәттән тыш хәлләрдән саклау өчен кирәкле көчләрне һәм чараларны әзерләү
һәм әзер булган хәлдә тоту турында
нигезләмә

1. Бу Нигезләмә Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау өчен билгеләнгән кирәкле көчләрне һәм чараларны (алга таба – көчләр һәм чаралар) әзерләү һәм әзер булган хәлдә тоту тәртибен билгели.

2. «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә көчләр һәм чаралар Татарстан Республикасы халкының һәм территориясенең тормыш эшчәнлеге иминлеген тәэмин итү өчен җитәрлек күләмдә булу һәм аларны мөмкин кадәр максималь файдалану принцибыннан чыгып төзелә һәм куллануга әзер булган хәлдә тотыла.

3. Көчләрне һәм чараларны әзерләү Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасын һәм граждannar оборонасы идарәсе органнарын, көчләрен әзерләү буенча оештыру-методик күрсәткечләр, шулай ук тиешле уку-укыту программалары нигезендә гражданнар оборонасы һәм халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү бердәм системасы кысаларында оештырыла.

4. Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы көчләрен һәм чараларын әзерләү үз эченә гадәттән тыш хәлләрне бетергәндә һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләрне башкарганда функциональ бурычларны уңышлы башкару өчен кирәкле белемнәр һәм практик күнекмәләр алу, әхлакый-психологик сыйфатлар формалаштыру чаралары комплексын ала.

5. Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасы көчләрен һәм чараларын әзерләү һәм әзер булган хәлдә тоту чаралары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән раслана торган гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча төп чаралар планнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау бурычларын үтәүгә көчләрнең һәм чараларның әзерлеген тикшерү максатларында Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министры урынбасары тарафыннан 2021 елның 28 августында расланган Гражданнар оборонасы, халыкны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын

куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү буенча укуларны һәм күнекмәләр алуны әзерләү һәм уздыру буенча методик тәкъдимнамәләр нигезендә команда-штаб, тактик-махсус өйрәнүләр, махсус өйрәнүләр һәм күнекмәләр алу, штабта һәм объектта күнекмәләр алу үткәрелә.

7. Көчләрне һәм чараларны карап тотуны финанс белән һәм матди-техник яктан тәэмин итү Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

8. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан федераль башкарма хакимият органнары көчләрен һәм чараларын җәлеп итү, әлеге органнар белән килештереп, Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.